Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәлңгеш авыл җирлеге Сәлңгеш авылында
гражданнар җыены КАРАРЫ

«19» ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәлңгеш авыл җирлеге Сәлңгеш авылы гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елда үзара салым кертү турында гражданнар җыенында каралуга чыгарылган мәсьәләгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәлңгеш авыл җирлеге Сәлңгеш авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2023 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Сәлңгеш авылында су белән тәэмин итү объектларын ремонтлау һәм төзекләндерү;
- Сәлңгеш авылы торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту» сүзләрен «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәлңгеш авыл җирлеге Сәлңгеш авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2023 елда 1200 (бер мең ике йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- Сәлңгеш авылында су белән тәэмин итү объектларын ремонтлау һәм төзекләндерү;
- Сәлңгеш авылы торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- Сәлңгеш авылы территориясен төзекләндерү» сүзләренә алыштырырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәлңгеш авыл җирлеге Сәлңгеш авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2023 елда 1200 (бер мең ике йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Сәлңгеш авылында су белән тәэмин итү объектларын ремонтлау һәм төзекләндерү;
- Сәлңгеш авылы торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- Сәлңгеш авылы территориясен төзекләндерү.

4. Халык җыенының нәтиҗәләрен «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәлңгеш авылының мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәлңгеш авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыены рәисе: А.Н. Пинин

Сәлңгеш авыл җирлеге башлыгы: А.Н. Пинин